# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлегенең Иске Өҗем торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

“09” ноябрь 2020 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Өҗемавыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Өҗем авыл җирлеге Советының 25.10.2019 ел №105 карары нигезендә, 2020 елның 09 ноябрендә «Сез 2021 елда Өҗем авыл җирлеге Иске Өҗем торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1. Территорияне төзекләндерү:
   - Иске Өҗем авылы территориясен төзекләндерү һәм чистарту (агач кисү, транспорт хезмәтләре күрсәтү, эш өчен түләү);

2. Иске Өҗем торак пунктында янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:
   - янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру эш өчен түләү;
   - янгын гидрантына кран сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 129 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 85 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Риза» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 85 кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Иске Өҗем авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

“Сез 2021 елда Өҗем авыл җирлеге Иске Өҗем торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1. Территорияне төзекләндерү:
   - Иске Өҗем авылы территориясен төзекләндерү һәм чистарту (агач кисү, транспорт хезмәтләре күрсәтү, эш өчен түләү);

2. Иске Өҗем торак пунктында янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:
   - янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру эш өчен түләү;
   - янгын гидрантына кран сатып алу - мәсьәләсен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Иске Өҗем авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Иске Өҗем авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Өҗем авыл җирлеге башлыгы: Вәлиев А.Т.